Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены
КАРАРЫ

25 ноябрь 2019 ел №1

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлегенә кергән Аграмак авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегенә кергән Аграмак авылында гражданнар җыены
Карары:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге составына керүче Аграмак авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча кабул ителгән карарны танырга:

-Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаны түбәндәге түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эш төрләрен башкаруга юнәлдерергә:

- Аграмак авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);
- Аграмак авылында юлларны кардан чистарту (МТЗ-82 тракторына ягулык сатып алу ,килешү буенча эш өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын ремонтлау (янгын сүндерү машинасы өчен з/частьләр сатып алу).
- Аграмак авылында чүплекләрне механикалаштырылган буртлау (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Аграмак авылында түбәндәге бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Авыл көне, « Халыкара өлкәннәр көне» , Бөек Җиңүнең 75 еллыгы, Яңа ел, ТАССРның 100 еллыгы, (бүләкләр, сувенирлар, канцелярия товарлары сатып алу);

4. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru Спас муниципаль районы рәсми сайтының

Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Аграмак авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Галәветдинова